КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 13 март г.Казань № 182

Бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, коммерциягә карамаган оешмаларның бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 13 март, 182 нче
карары белән расланды

# Бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында, коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә эшләнде һәм бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү өчен коммерциягә карамаган оешмаларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш) (алга таба – коммерциягә карамаган оешмалар) Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр коммерциягә карамаган оешмаларның бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүне гамәлгә ашыру чыгымнарын финанслар белән тәэмин итү максатларында бирелә.

3. Субсидияләр коммерциягә карамаган оешмаларга тиешле финанс елына субсидия бирү өчен бюджет акчасын алучы буларак Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (алга таба – Министрлык) билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

Министрлык субсидия бирүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора.

4. Гариза бирү көненә карата коммерциягә карамаган оешмаларны сайлап алу критерийлары:

коммерциягә карамаган оешманың төп эшчәнлек юнәлешләре бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга туры килү;

коммерциягә карамаган оешма штатында һәм/яки юридик затлар штатында «Бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 ел, 29 июль, ФЗ-135 нче Федераль законның 16.2 статьясы таләпләренә җавап бирүче бәяләүчеләрнең үз-үзен җайга салучы оешмалары экспертларының (алга таба – экспертлар) коммерциягә карамаган оешмасы әгъзалары булу.

5. Субсидияләр субсидия бирү турындагы килешүне (алга таба – килешү) төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан булган айның беренче көненә түбәндәге таләпләргә туры килүче коммерциягә карамаган оешмаларга бирелә:

Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмаган;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар

нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләнмәгән башка бурычлары булмаган;

үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процессында булмаган;

законнар белән билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм эшчәнлеген Татарстан Республикасы территориясендә гамәлгә ашырган;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан башка норматив хокукый актлар нигезендә акча алмаган.

6. Субсидия алу өчен коммерциягә карамаган оешмалар түбәндәге документларны Министрлыкка тапшыра:

Министрлык тарафыннан расланган форма буенча субсидия алуга гариза;

коммерциягә карамаган оешманың билгеләнгән тәртиптә расланган гамәлгә кую документлары күчермәләрен;

гариза бирү көненә карата коммерциягә карамаган оешма әгъзалары реестрыннан коммерциягә карамаган оешма әгъзалары турындагы тәңгәлләштерү мәгълүматлары булган өземтәне;

бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл иткәндә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтүгә җәлеп итүче экспертлар турындагы мәгълүматны;

экспертның фамилиясен, исемен, атасының исемен;

эксперт штатта торган оешманың исемен, биләгән вазыйфасын, соңгы биш ел эшләү дәвере өчен хезмәт кенәгәсеннән өземтә;

оешманың исемен күрсәтеп, бәяләүчеләрнең үз-үзен җайга салучы оешмаларының ачык мәгълүматлар (реестрлар) базаларындагы реестр номерын;

бәяләүчеләрнең үз-үзен җайга салучы оешмасының «Бәяләү эшчәнлеге турында» 1998 ел, 29 июль, ФЗ-135 нче Федераль законның 17.1 статьясы нигезендә эшләүче үз-үзен җайга салучы оешманы эксперт итеп билгеләү турындагы карары күчермәсен;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары сораулары буенча бәяләү эшчәнлеге өлкәсендә соңгы биш ел эчендә башкарылган, сорауның һәм эксперт бәяләмәсенең тәңгәлләштерү мәгълүматлары бирелгән эксперт бәяләмәләре реестрын;

соңгы биш ел эчендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тәкъдимнәре буенча эшләнгән, Татарстан Республикасында күчемсез мөлкәт объектлары, җир кишәрлекләре һәм аренда ставкалары бәяләре мониторингы рәвешендә башкарылган аналитик тикшеренүләрнең басма формада бирелә торган оригинал-макетларын;

кредит оешмасында ачылган, субсидия күчерелә торган хисап исәбе турындагы мәгълүматны;

финанс-икътисадый нигезләүне теркәп, бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан расланган чыгымнар сметасын;

салым органының килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан булган

айның беренче көненә карата Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият түләүләре, пенялар, штрафлар, процентларны түләү буенча башкарылмаган йөкләмәләре булмауны раслый торган белешмә кәгазен;

килешү төзергә планлаштырыла торган ай алдыннан булган айның беренче көненә карата коммерциягә карамаган оешманың үзгәртеп оештыру, бетерү, банкротлык процедураларында булмавы турындагы, шулай ук Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) кире кайтару буенча үз вакытында түләнмәгән бурычлары һәм Татарстан Республикасы бюджеты каршында үз вакытында түләмәгән башка бурычлары булмавы турындагы коммерциягә карамаган оешма җитәкчесе тарафыннан имзаланган гарантия хатын;

коммерциягә карамаган оешма штатында һәм/яки юридик затлар штатында, фамилиясен, исемен, атасының исемен һәм штат расписаниесе буенча вазыйфасын күрсәтеп, экспертларның коммерциягә карамаган оешмасы әгъзалары булу турындагы мәгълүматны.

Коммерциягә карамаган оешма бу пунктның ундүртенче абзацы белән күздә тотылган документны тапшырмаган очракта, Министрлык әлеге документны дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә соратып ала.

7. Субсидия бирүгә гаризалар кабул итү турындагы белдерү Министрлыкның рәсми сайтында (http://mzio.tatarstan.ru) басылып чыга. Белдерүдә Министрлыкның документлар кабул итүне гамәлгә ашыручы структур бүлекчәсе күрсәтелә. Коммерциягә карамаган оешмаларның субсидия алуга гаризаларын бирү вакыты белдерү басылып чыккан көннән 10 календарь көн тәшкил итә.

8. Документлар кәгазь чыганакта тапшырыла. Тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы өчен коммерциягә карамаган оешмалар закон нигезендә җавап бирә.

9. Министрлык гаризаны кергән көнне терки һәм гаризаны теркәгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә тапшырылган документларны карап тикшерә һәм субсидия бирү турында яки аны бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

10. Субсидия бирүгә гаризаларны бәяләү критерийлары:

коммерциягә карамаган оешма штатында һәм/яки юридик затлар штатында экспертлар – коммерциягә карамаган оешма әгъзалары саны;

соңгы биш ел эчендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары сораулары буенча бәяләү эшчәнлеге өлкәсендә башкарылган эксперт бәяләмәләре саны;

соңгы биш ел эчендә Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары тәкъдимнәре буенча эшләнгән, Татарстан Республикасында күчемсез мөлкәт объектлары, җир кишәрлекләре һәм аренда ставкалары бәяләре мониторингы рәвешендә башкарылган аналитик тикшеренүләр саны;

Гаризалар һәр критерий буенча аларны рангларга бүлү юлы белән аерым бәяләнә (N нан 1 гә кадәр, монда N – тапшырылган гаризалар саны). N рангы тапшырылган гаризалар арасында күрсәткечнең иң зур мәгънәсенә ия булган һәр

критерий буенча бирелә. N минус 1, N минус 2 һәм башка (1 гә кадәр) ранглар шул ук эзлеклелектә кечкенә мәгънәгә ия булган критерийларга бирелә.

Субсидия N суммасы буенча гаризасы иң зур мәгънә ия булган гариза бирүчегә бирелә. N суммасы буенча гаризалар тигез булганда, барлык критерийлар күрсәткечләре суммасы буенча иң зур мәгънәгә ия булган гариза җиңеп чыга.

11. Субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

бу Тәртипнең 6 нчы пунктындагы икенче – унөченче, унбишенче абзацлар белән күздә тотылган документлар тапшырылмау (тулы булмаган күләмдә тапшырылу);

бу Тәртипнең 6 нчы пунктында күрсәтелгән документларда бирелгән мәгълүмат дөрес булмау;

коммерциягә карамаган оешма бу Тәртипнең 5 нче пунктында күрсәтелгән таләпләргә һәм бу Тәртипнең 4 нче пунктында күрсәтелгән сайлап алу критерийларына туры килмәү;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка билгеләнгән тәртиптә ирештерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары булмау.

12. Министрлык боерык рәвешендәге карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче өч көн эчендә гариза биргән коммерциягә карамаган оешмага субсидия бирү турындагы яки субсидия бирүдән баш тарту турындагы кабул ителгән карар хакында язма рәвештә хәбәр итә.

13. Субсидия бирү Министрлык һәм субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән коммерциягә карамаган оешма (алга таба – субсидия алучы) арасында төзелгән килешү нигезендә гамәлгә ашырыла. Килешү субсидия бирү турындагы карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче биш көн эчендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала:

субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше;

бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен чыгымнар төрләре;

субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләре;

субсидия күчерү тәртибе;

субсидиядән файдалану турында, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләренә ирешү турында хисаплылык бирү вакытлары һәм формасы;

агымдагы финанс елында субсидия алучы тарафыннан хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләрен кире кайтару очраклары;

Министрлык, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы белән килештереп, аларны файдалануга ихтыяҗ булу турындагы карар кабул иткән очракта, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлешләре финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып торган чыгымнарны гамәлгә ашыру мөмкинлеген күздә тота торган шарт;

субсидия алучының һәм субсидияләр бирү турындагы шартнамәләр (килешүләр) буенча йөкләмәләрне башкару максатларында төзелгән шартнамәләр (килешүләр) буенча тәэмин итүчеләр (подрядчылар, башкаручылар) булып торган затларның Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы

тарафыннан субсидия алучының аны бирү шартларын, максатларын һәм тәртибен үтәвенә тикшерүләр үткәрүгә ризалыгы;

алынган акча исәбеннән чит ил валютасы сатып алуны тыю (югары технологияле чит ил җиһазлары, чимал һәм комплектлау әйберләре сатып алганда (кайтартканда) Россия Федерациясе валюта законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган операцияләрдән тыш);

субсидия алучының бу Тәртип һәм төзелә торган килешү шартларын үтәве турындагы нигезләмәләр.

14. Министрлык субсидияне субсидия алучының Россия кредит оешмасында ачылган исәп-хисап исәбенә бер тапкыр килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнүче 20 көн эчендә күчерә.

15. Финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарның түбәндәге юнәлешләрен билгеләргә:

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатларга бәйле булган эшләрне башкару өчен гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителүче затларның һәм коммерциягә карамаган оешмадагы штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр өчен түләү;

мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алу;

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатларга бәйле булган эшләрне башкару өчен гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп итүче затларның һәм коммерциягә карамаган оешмадагы штат хезмәткәрләренең командировка чыгымнары;

мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләве;

физик һәм юридик затлар хезмәтләре, шул исәптән экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре, элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр һәм аларга бәйле булган башка хезмәтләр өчен түләү;

кулланыла торган программа продуктларының, шул исәптән:

мәгълүмати-белешмә программаларының;

ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының;

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатлар өчен кирәкле башка программа продуктларының эшләвен тәэмин итү һәм актуальләштерү өчен түләү;

коммерциягә карамаган оешма сайтының эшләвен тәэмин итү һәм аны модернизацияләү өчен түләү;

алга таба алып сату өчен билгеләнмәгән полиграфия продукциясен сатып алу (җитештерү);

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатларны тормышка ашыру өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алу;

бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүдә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтү өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацияле

проектны (программаны) тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булган оештыру чыгымнары.

16. Субсидия күләме, шундый ук товарларның, эш башкаруларның, хезмәт күрсәтүләрнең базар бәяләре турындагы мәгълүматка анализ бирүдән чыгып, түбәндәге формуланы кулланып билгеләнә:

$$С = З_1 + З_2 + З_3 + ... + З_n,$$

монда:

С – субсидия алучыга бирелә торган субсидия күләме;

$З_1$, $З_2$, $З_3$, ..., $З_n$ – составына түбәндәгеләргә бәйле булган, нигезләнгән һәм документлар белән расланган чыгымнар керә торган һәм бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатларга чыгымнар:

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатларга бәйле булган эшләрне башкару өчен гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителүче затларның һәм коммерциягә карамаган оешмадагы штат хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләүгә;

Россия Федерациясе бюджет системасының тиешле дәрәҗәдәге бюджетына салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре һәм башка мәҗбүри түләүләр өчен түләүгә;

мөлкәт хокукларын, шул исәптән интеллектуаль эшчәнлек нәтиҗәләренә хокукларны сатып алуга;

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатларга бәйле булган эшләрне башкару өчен гражданлык-хокукый характердагы шартнамәләр буенча җәлеп ителүче затларның һәм коммерциягә карамаган оешмадагы штат хезмәткәрләренең командировка чыгымнарына;

мөлкәттән файдаланган өчен аренда түләвенә;

физик һәм юридик затлар хезмәтләре, шул исәптән экспертлар һәм эксперт оешмалары хезмәтләре, элемтә хезмәтләре, транспорт хезмәтләре, коммуналь хезмәтләр, мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр һәм аларга бәйле булган башка хезмәтләр өчен түләүгә;

кулланыла торган программа продуктларының, шул исәптән:

мәгълүмати-белешмә программаларының;

ведомствоара электрон документлар әйләнеше системасының;

коммерциягә карамаган оешма сайтының;

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатлар өчен кирәкле башка программа продуктларының эшләвен тәэмин итү һәм актуальләштерү өчен түләүгә;

алга таба алып сату өчен билгеләнмәгән полиграфия продукциясен сатып алуга (җитештерүгә);

бу Тәртипнең 2 нче пункты белән күздә тотылган максатларны тормышка ашыру өчен төп чаралар һәм матди запаслар сатып алуга;

бәяләү эшчәнлегенә бәйле булган социаль әһәмиятле мәсьәләләрне хәл итүдә эксперт һәм консультация ярдәме күрсәтү өлкәсендә яңа, шул исәптән инновацияле

проектны (программаны) тормышка ашыруга турыдан-туры бәйле булган оештыру чыгымнарына.

17. Субсидия алучылар субсидиядән файдалану турындагы, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәлелегенең билгеләнгән күрсәткечләренә ирешү турындагы хисапны Министрлыкка килешү белән күздә тотылган вакытларда һәм форма нигезендә кертә.

Субсидиядән нәтиҗәле файдалануны бәяләү Министрлык тарафыннан субсидия бирү нәтиҗәлелегенең түбәндәге күрсәткечләре буенча гамәлгә ашырыла:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары сораулары буенча бәяләү эшчәнлеге өлкәсендә башкарылган эксперт бәяләмәләре саны;

Татарстан Республикасында күчемсез мөлкәт объектлары, җир кишәрлекләре һәм аренда ставкалары бәяләре мониторингы формасында башкарылган аналитик тикшеренүләр саны.

18. Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы субсидия алучыларга субсидия бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлүен законнар нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыра.

19. Субсидия түбәндәге очракларда Министрлыкның тиешле таләбен алган көннән эш көннәрендә исәпләнүче 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш:

субсидия алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән, Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча ачыкланган шартлар бозылган;

субсидия алучы тарафыннан субсидия алу өчен дөрес (тулы) булмаган мәгълүматлар һәм документлар тапшырылган;

субсидиядән файдалану турындагы хисап килешү белән билгеләнгән вакытта тапшырылмаган;

субсидия акчасы максатчан файдаланылмаган;

субсидияләр бирү нәтиҗәлелеге күрсәткечләре мәгънәләренә ирешелмәгән.

20. Килешү белән күздә тотылган очракларда, хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган өлеше субсидия алучы тарафыннан хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш. Министрлык тарафыннан әлеге акчаны файдалануга ихтыяҗ булу турында карар кабул ителгәндә, алар финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып хисап финанс елында субсидиянең файдаланылмый калган тиешле өлеше торган чыгымнарны гамәлгә ашыруга юнәлдерелергә мөмкин.

21. Субсидия алучы тарафыннан бу Тәртипнең 19 һәм 20 нче пунктларында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару вакытлары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнүче җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

22. Субсидияләрне максатчан һәм нәтиҗәле файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

---